«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы

_____А.Х. Гыйльметдинов

"29" декабрь 2010 нчы ел

«КИЛЕШЕНГӘН»

Татарстан Республикасы
Мәгарифне үстерү институты
ректоры

_____ Р.Ф. Шәйхелисламов

"27" декабрь 2010 нчы ел

ТАТАР ТЕЛЕ

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпләрнең рус төркемнәренең чыгарылыш сыйныф укучылары өчен 2011 нче елгы бердәм республика имтиханы өчен татар теленнән контроль бәяләү материалларының күрсәтмә варианты

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының
бердәм дәүләт имтиханы оештыру бүлеге тарафыннан әзерләнде

ТАТАР ТЕЛЕННӘН БЕРДӘМ РЕСПУБЛИКА ИМТИХАНЫ

Эшне башкару өчен күрсәтмә

Татар теленнән имтихан эшен башкаруга 3 сәгать (180 минут) вакыт бирелә. Имтихан эше 3 өлештән тора.

Беренче өлеш 30 биремне (А1 – А30) үз эченә ала. Һәр биремгә китерелгән 4 вариант җавапның сез берсен, ягъни дөресен генә сайлап алырга тиешсез.

Икенче өлеш 8 биремнән (В1 – В8) тора. Бу биремнәргә җавапларны мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга кирәк.

Өченче өлештә сезгә бер бирем (С) тәкъдим ителә. Сез бирелгән текст буенча язма эш (инша) язарга тиешсез.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәргә киңәш итәбез. Биремнәрне үтәү барышында кыенлык тудырганнары килеп чыккан очракта, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә мөмкин. Вакытыгыз калган очракта, сез бу биремнәргә кабат әйләнеп кайта аласыз.

Дөрес җавап, катлаулылыгыннан чыгып, бер яки югарырак балл белән бәяләнә. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, сезнең гомуми балларыгыз чыгарыла. Шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

Уңышлар телибез!

Единый республиканский экзамен по татарскому языку

Инструкция по выполнению работы

На выполнение экзаменационной работы по татарскому языку дается 3 часа (180 минут). Работа состоит из 3-х частей.

Часть 1 включает 30 заданий (А1 – А30). К каждому из них даны 4 варианта ответа, из которых только один правильный.

Часть 2 состоит из 8 заданий (В1 – В8). Ответы к этим заданиям Вы должны сформулировать самостоятельно.

Часть 3 состоит из одного задания (С) и представляет собой письменную работу по тексту (сочинение).

Советуем выполнять задания в том порядке, в котором они даны. Для экономии времени пропускайте задание, которое не удается выполнить сразу, и переходите к следующему. Если после выполнения всей работы у Вас останется время, то можно вернуться к пропущенным заданиям.

Правильный ответ в зависимости от сложности каждого задания оценивается одним или более баллами. Баллы, полученные Вами за все выполненные задания, суммируются. Постарайтесь выполнить как можно больше заданий и набрать как можно больше баллов.

Желаем успехов!

1 нче өлеш

При выполнении заданий этой части в бланке ответов № 1 под номером выполняемого задания (А1 - А30) поставьте знак «Х» в клеточку, номер которой соответствует номеру выбранного вами ответа.

А1 **[йы] авазлары булган сүзне табыгыз.**

1) җиңел
2) егет
3) елак
4) көзге

А2 **Орфографик хаталы җөмләләрне табыгыз.**

А) Дустымның туганнары ерак Себердә яшиләр.
Ә) Без имтиханнарны яхшы билгеләренә генә тапшырырга тырышабыз.
Б) Бороңгы гасырларда кешеләр утны таш ярдәмендә тапканнар.
В) Физика дәресендә без гәмәли эшләр башкардык.

1) А, Б
2) Ә, Б
3) Б, В
4) А, В

А3 **Хаталы сүзне табыгыз.**

1) гөрләвек
2) инеш
3) куак
4) боролыш

А4 **Хаталы сүзне табыгыз.**

1) ямь-яшел
2) алсу
3) җете кызыл
4) шәмәһә

А5 **Орфографик хаталы җөмләне табыгыз.**

1) Бүген мәдәният хезмәткәрләре көне.
2) Сабантуй бәйрәме ел саен җәй көне үткәрелә.
3) Апам гарәп сәнгате белән кызыксына.
4) Үз җавабыннан Марат кәнагәть калды.

А6 **Сүзнең дөрес язылышын табыгыз.**

1) кәгазь
2) кагәзь
3) кәгәз
4) кагазь

А7 **Ясалма исемне табыгыз.**

1) китап
2) калак
3) кунак
4) колак

А8 **Кушма исемне табыгыз.**

1) ап-ак
2) аккош
3) атом-төш
4) һичкем

А9 **Кушма җөмләне табыгыз.**

1) Билгеле: алар һичшиксез сезне тыңларлар.
2) Бүген дә, иртәгә дә кар явачак.
3) Җырларда җырланган, күп әсәрләрдә сөйләнгән Казан шул инде.
4) Алар, бик арысалар да, юлларын дәвам иттеләр.

А10 **Сүзнең дөрес тәрҗемәсен табыгыз.**

Исәпләнә - ...

1) считают
2) решается
3) количество
4) насчитывается

А11 **Кисәкчәне табыгыз.**

1) һәм
2) иң
3) белән
4) кебек

А12 **Кайсы раслау дөрес түгел?**

1) *Дустым* сүзендә басым икенче иҗеккә төшә.
2) *Кайтыгыз* сүзендә басым беренче иҗеккә төшә.
3) *Бармыйлар* сүзендә басым өченче иҗеккә төшә.
4) *Кычкырып* сүзендә басым өченче иҗеккә төшә.

Җөмләләрне укыгыз һәм А 13 – А 16 биремнәрен үтәгез.

А. Бәйрәм күңелле үтте, һәм һәр әни үз улы яки кызы белән горурланып утырды.
Ә. Соңрак без бергәләп концерт программасын төзедек.
Б. Иң беренче эшебез шул булды: һәркем үз әнисе хөрмәтенә я җыр, я шигырь, я бию өйрәнергә тиеш иде.
В. Әниләр көненә без инде әзерләнә башладык.

А13 **Текст булсын өчен, җөмләләрне нинди тәртиптә урнаштырырга кирәк?**
1) Ә, А, Б, В
2) Б, Ә, А, В
3) В, А, Ә, Б
4) В, Б, Ә, А

А14 **Кайсы җөмләдәге сүз “ *либо*” дип тәрҗемә ителә?**
1) Б 2) В 3) А 4) Ә

А15 **Кайсы җөмләдә беренче зат тартымлы исем бар?**
1) В 2) А 3) Ә 4) Б

А16 **Кайсы җөмләдә вакыт рәвеше бар?**
1) Ә 2) В 3) А 4) Б

А17 **Сүзнең тәрҗемәсен табыгыз.**
Соревнование
1) көрәш 2) ялгыш
3) ярыш 4) уңыш

А18 **Сүзнең дөрес язылышын табыгыз.**
1) таяк
2) тайак
3) тайяк
4) тайәк

А19 **Хаталы сүзне табыгыз.**
1) тимераяк
2) кәшәкә
3) чангы
4) көймә

A20 **Кайсы җөмләдә өтер (,) куела?**

1) Иртәгә я мин сезгә барырмын () я үзегез килерсез.
2) Мин беләм () син моны башкарып чыгачаксың.
3) Укытучы такта янына дустымны я () мине чыгарачак.
4) Син безгә берәр шәһәрнең тарихын ( ) сөйлә әле.

A21 **Кайсы җөмләдә *күренекле* сүзен кулланып була?**

1) Мәктәпне тәмамласак та, ... сыйныфташлар белән очрашып торырга телибез.
2) Шәһәребездә ел саен зур биналар,... корылмалар төзелә.
3) Бу китапны укырга миңа укытучыбыз киңәш итте, ләкин мин ... китапханәдән таба алмадым.
4) Дустым сынлы сәнгать белән кызыксына, шуңа күрә ... рәссамнарның күргәзмәләренә еш йөри.

A22 **Кайсы җөмләдә сызык (-) куела?**

1) Мөгаен () иртәгә соңгы дәресебез булмас.
2) Әтием ( ) дөньякүләм танылган оешманың баш хисапчысы.
3) "Сабантуй" газетасы ( ) һәр укучыга киңәш бирә ала.
4) Соңга калуымның сәбәбе шул ( ) автобус булмады.

A23 **Җөмләнең башын табыгыз.**

... һәр эшне үз вакытында башкарырга кирәк ди.

1) Мәкаләнең исеме
2) Китаптагы фикерләр
3) Татар мәкале
4) Язмамны тәмамлап,

A24 **Җөмләнең дөрес тәрҗемәсен табыгыз.**

Существуют различные мнения.

1) Төрле фикерләр бар.
2) Төрле карашлар яши.
3) Күптөрле кешеләр бар.
4) Теләкләр бик күп.

A25 **Җөмләнең дөрес тәрҗемәсен табыгыз.**

Бу кагыйдәне һәркем үтәргә тиеш.

1) Каждый должен выполнять этот закон.
2) Все хотят жить по этому закону.
3) Каждый должен соблюдать это правило.
4) Каждое правило должно соблюдаться.

А26 **Иярченле кушма җөмләне табыгыз.**

1) Теләге бар кешеләр бу фильмны "Мираж" кинотеатрында карый алалар.

2) Алар – Киевка, ә без Мәскәүгә барачакбыз.

3) Ярыштан арып кайтсак та, бу кичәгә, һичшиксез, барачакбыз.

4) Апасы да, абыйсы да, барлык туганнары да аның уңышларына бик сөенделәр.

Текстны укыгыз һәм А 27 –А 30; В 1 – В 8; С биремнәрен эшләгез.

(1) Яхшы кешенең дуслары күп була. (2) Һәрвакыт үзен генә кайгырткан, тар күңелле кешене чын дус итү кыен. (3) Кайберәүләр турында: «Ай, аның дуслары күп!»- диләр. (4) Бу бик зур мактау сүзе булып яңгырый. (5) Киң күңелле, ачык йөзле, ярдәмчел кешеләрнең дуслары күп була бит! (6) Андыйлар үз тирәләренә дә яхшы кешеләрне җыялар, иптәшләрен үзара таныштырып, якынайтып бетерәләр. (7) «Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын!» - ди халык. (8) Димәк, бер кешенең йөз дусты була ала. (9) Бу – бик яхшы!

(10) Чын дуслык ул – башка берәүгә яраклашып яшәү генә түгел. (11) Була шундый очраклар: шактый вакыт дус булып йөргән берәүнең кимчелекләре күренә башлый. (12) Чын дус үзенә якын кешенең хаталарын бетерергә тырыша. (13) Ул моны шундый сак эшли ки, дустының ачуы да килми, күңеле дә рәнҗеми.

(14) Чын дуслык авырлык килгән чакта сынала. (15) Шатлыкны уртаклашучылар күп булса да, кайгы килә калса, алар каядыр юкка чыга. (16) Мондый чакта таяныр кешең булу – зур бәхет.

(17) Шуны да онытырга ярамый: дуслык беркайчан да берьяклы гына булмый. (18) Җаваплы, ярдәмчел, үз-үзләренә таләпчән кешеләр генә чын дус була алалар.

(М.Маликовадан)

А27 **1нче абзацта кайсы сүзнең антонимы бирелгән?**

1) җиңел
2) акыллы
3) әйбәт
4) матур

А28 *Киң күңелле* -

1) широкая душа
2) щедрая рука
3) мягкое сердце
4) надежный тыл

А29 **Сүзнең дөрес транскрипциясен табыгыз.**

1) [йәрдәмчел] 2) [йәрдәмчэл]
3) [ярдәмчел] 4)[ярдәмчэл]

А30 **Кайсы раслау текстның эчтәлегенә туры килми?**

1) Дуслар һәрвакыт бер-берсенә ярдәм итәләр.
2) Дуслык берьяклы гына булмый.
3) Безнең дуслык мәңгелек.
4) Дусларың күп булу - зур байлык.

2 нче өлеш

При выполнении заданий этой части запишите ваш ответ в бланке ответов № 1 справа от номера задания (В1 – В8), начиная с первой клеточки. Каждую букву или цифру пишите в отдельной клеточке. Слова пишите без пробелов, между числами в отдельной клеточке ставьте запятую.

В1 – В3 биремнәренә җавапларны сүзләр белән языгыз.

В1 1 нче абзацтан үткән заман сыйфат фигыльне табып языгыз.

В2 1 нче абзацтан ымлыкны табып языгыз.

В3 1 нче абзацтан зат алмашлыгын табып языгыз.

В4 – В8 биремнәренә җавапларны саннар белән языгыз.

В4 1 нче абзацтан кереш сүзле җөмләне табыгыз һәм санын языгыз.

В5 1 нче абзацтан тиңдәш аергычлы җөмләләрне табыгыз һәм саннарын языгыз.

В6 12-18 нче җөмләләрдән исем хәбәрле җөмләне табыгыз һәм санын языгыз.

В7 1 нче абзацтан тиңдәш хәбәрле җөмләне табыгыз һәм санын языгыз.

В8 Текстган иярченле кушма җөмләләрне табыгыз һәм саннарын арта бару тәртибендә языгыз.

3 нче өлеш

Для ответа к заданию этой части используйте бланк ответов № 2. Запишите сначала номер задания С1, а затем напишите сочинение.

С1 Укылган текстның эчтәлегенә карата үз мөнәсәбәтегезне белдереп, 120 сүздән дә ким булмаган инша (сочинение) языгыз. Текстта сүз нинди проблемалар турында бара? Авторның аларга мөнәсәбәте нинди? Фикерләрегезне дәлилләгез.

Татар теленнән имтихан эшен бәяләү системасы

1 нче өлеш җаваплары

Биремнәр	Дөрес җавап		Биремнәр	Дөрес җавап
A1	3		A16	1
A2	3		A17	3
A3	4		A18	1
A4	4		A19	3
A5	4		A20	1
A6	1		A21	4
A7	3		A22	2
A8	2		A23	3
A9	1		A24	1
A10	4		A25	3
A11	2		A26	1
A12	3		A27	1
A13	4		A28	1
A14	1		A29	2
A15	4		A30	3

2 нче өлеш җаваплары

B1, B2, B3, B4, B5, B6, B7 биремнәренә дөрес җавап 1 балл, хата җавап яки аның булмавы 0 балл белән бәяләнә.

B1	кайгырткан
B2	ай
B3	аның
B4	8
B5	2,5
B6	16
B7	6
B8*	3, 11, 14,17

* B8 биреме 0 – 4 балл арасында бәяләнә. Дөрес билгеләнгән һәр сан өчен 1 балл куела (4 балл: хаталар юк; 3 балл: 1 хата бар; 2 балл: 2 хата бар; 1 балл - бер генә сан дөрес күрсәтелгән; 0 балл: тулысынча хата җавап (саннарның дөрес бул
маган җыелмасы) яки аларның язылмавы). Җавапта саннарны язу тәртибе мөһим

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпләрнең рус төркемнәренең чыгарылыш сыйныф укучылары өчен(20/3) имтихан эшен бәяләү критерийлары

Язма эшне бәяләү критерийлары

№	С1 биременең җавабын бәяләү критерийлары	Баллар
I	***Иншаның эчтәлеге***	
К1	**Чыганак тексттагы проблемаларны формалаштыру**	
	Имтихан бирүче чыганак тексттагы проблемаларның берсен теге яки бу формада дөрес формалаштырган. Проблеманы аңлау яки формалаштыруга бәйле фактик хаталар юк.	1
	Имтихан бирүче чыганак тексттагы проблемаларның берсен дә дөрес формалаштыра алмаган.	0
К2	**Чыганак текстның формалаштырылган проблемасын аңлату**	
	Имтихан бирүче формалаштырган чыганак текст проблемасы аңлатылган. Язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле фактик хаталар юк.	2
	Имтихан бирүче формалаштырган чыганак текст проблемасы аңлатылган, **ләкин** язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле 1 фактик хата бар.	1
	Имтихан бирүче формалаштырган проблема аңлатылмаган, **яки** язмасында чыганак текст проблемасын аңлауга бәйле 1дән артык фактик хатасы бар, **яки** имтихан бирүче формалаштырмаган башка проблема аңлатылган, **яки** аңлатмалар урынына язмада текстның яки аның өзегенең эчтәлеге генә бирелгән, **яки** аңлатмалар урынына чыганак тексттан күләмле өзек кенә китерелгән.	0
К3	**Чыганак текст авторының позициясен чагылдыру**	
	Имтихан бирүче чыганак текст авторының аңлатылган проблемага бәйле позициясен дөрес формалаштырган. Чыганак текст авторының позициясен аңлауга бәйле фактик хаталар юк.	1

	Автор позициясен аңлауда фактик хаталар юк.	
	Чыганак текст авторының позициясе имтихан бирүче тарафыннан дөрес формалаштырылмаган, **яки** чыганак текст авторының позициясе формалаштырылмаган.	0
К4	**Имтихан бирүченең проблемага карата үз фикерен дәлилләве**	
	Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы күтәреп чыккан проблема буенча, үз фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, дәлилләгән (**2 дән ким булмаган дәлил китергән, шуларның берсе матур, публицистик яки фәнни әдәбиятка карый**).	3
	Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы күтәреп чыккан проблема буенча, үз фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, **2 дән ким булмаган** дәлил китергән), **яки** **матур, публицистик яки фәнни әдәбиятка караган 1 генә дәлил китергән**.	2
	Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы күтәреп чыккан проблема буенча, үз фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып дәлилләгән (**1** дәлил китергән).	1
	Имтихан бирүче үзе формалаштырган һәм текст авторы күтәреп чыккан проблема буенча, үз фикерен (автор позициясе белән килешеп яки килешмичә) белдергән, **ләкин дәлилләмәгән,** **яки** имтихан бирүче фикере формаль рәвештә генә (мәсәлән, “Мин автор фикере белән риза / риза түгел”) бирелгән, **яки** имтихан бирүче фикере язмада бөтенләй чагылыш тапмаган.	0
II	***Иншаның тел ягы***	
К5	**Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге.**	
	Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана: – логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган; – абзацларга бүленештә хаталар юк.	2
	Имтихан бирүченең эше мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана, **ләкин** 1 логик хатасы бар, **һәм/яки**	1

	абзацларга бүленештә **1** урында хата бар.	
	Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар, **ләкин** логик хаталарның саны 1 дән артык, **һәм/яки** абзацларга бүленештә **2** урында хата бар.	0
К6	**Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы**	
	Язмада имтихан бирүченең фикере төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган.	2
	Язмада фикер төгәл, **ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган, **яки** язмада төрле грамматик формалар кулланылган, **ләкин** фикер төгәллеге бозылган.	1
	Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган.	0
III	***Грамоталылык***	
К7	**Орфографик нормаларның үтәлеше**	
	2 орфографик хатасы бар	3
	3-4 хата җибәрелгән	2
	5-6 хатасы бар	1
	Хаталарының саны 6 дан артык	0
К8	**Пунктуацион нормаларның үтәлеше**	
	2 пунктуацион хатасы бар	3
	3-4 хатасы бар.	2
	5-6 хатасы бар	1
	Хаталарының саны 6 дан артык	0
К9	**Тел нормаларының үтәлеше**	
	2 грамматик хатасы бар	2
	3–5 хатасы бар	1
	Хаталарының саны 5 тән артык.	0
К10	**Сөйләм нормаларының үтәлеше**	
	Сөйләмгә кагылышлы 4 хатасы бар	2
	5–6 хатасы бар.	1
	Хаталарының саны **6** дан артык.	0
К11	**Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше**	
	Этикага кагылышлы хаталары юк.	1
	Хаталары бар.	0
К12	**Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше**	
	Фактик хаталары юк.	1
	Фактик хаталары бар.	0
Язма эш өчен максималь балл		**23**

Грамоталылыкны (К7-К12) бәяләгәндә, укучы язмасының күләме исәпкә алына. Таблицада күрсәтелгән бәяләү нормалары күләме 120 яки артыграк сүздән торган (16-18 җөмлә) язмаларны бәяләү өчен тәкъдим ителә.

Әгәр укучының язмасы 60 сүздән дә кимрәк булса, андый эш 0 балл белән бәяләнә, бирем үтәлмәгән булып санала.

Әгәр укучының язмасы 60 сүздән 120 сүзгә кадәр күләмдә булса, К7-К10 нчы критерийлардагы хаталары киметелә. **Бу критерийлар буенча 2 балл түбәндәге очракларда куела:**

К7 – 2 орфографик хатасы бар;

К8 – тыныш билгеләренә кагылышлы 2 хатасы бар.

Бу критерийлар буенча 1 балл түбәндәге очракларда куела:

К7 – 3-4 хатасы бар;

К8 – 3-4 хатасы бар;

К9 – 2 грамматик хатасы;

К10 – сөйләмгә кагылышлы 4 хатасы бар.

Әгәр укучының язмасы 60 сүздән 120 сүзгә кадәр күләмдә генә булса, К7-К12 критерийлары буенча югары балл бөтенләй куелмый.

Әгәр укучының язмасында автор текстының эчтәлеге генә чагылыш тапса яки автор тексты бернинди аңлатмаларсыз күчереп кенә алынган булса, К1-К12 нче критерийлары буенча бу эш 0 балл белән бәяләнә. Чыганак текстка нигезләнмичә язылган эш бәяләнми.